**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 20 июнь | № 447

г. Казань

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә ярдәм итү максатларында, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны үткәрүдә булышлык күрсәтү һәм аларны әзерләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча бу карарга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән составта эшче төркем төзергә.

2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлегенә – Татарстан Республикасы Милли банкына, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрүгә комиссияләргә бүленеп бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән операцияләр башкару өчен, законнар белән билгеләнгән тәртиптә сайлау комиссияләренең счетларын ачуны тәэмин итүне;

«Россия Саклык банкы» ачык акционерлык җәмгыятенең «Татарстан Банкы» 8610 нчы бүлегенә законнар белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатларның махсус сайлау счетларын ачуны тәэмин итүне.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль законның 19 статьясы һәм Татарстан Республикасы Сайлау

кодексының 27 статьясы белән билгеләнгән тәртип һәм вакытлар нигезендә, сайлаучыларның вакытлыча тору урыннарында (хастаханәләр, шифаханәләр һәм ял йортлары, шикләнелүче һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту урыннары һәм башка вакытлыча тору урыннары) сайлау участоклары оештыруга булышлык күрсәтүне, шулай ук тиешле участок сайлау комиссияләренең сайлау нәтиҗәләре турында сайлау бюллетеньнәрен, беркетмәләрен – югарыдагы сайлау комиссияләренә, бүтән сайлау документларын күрсәтелгән сайлау участокларында оештырылган участок сайлау комиссияләренә илтеп тапшыруда булышлык күрсәтүне тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына бу пункт белән күздә тотылган чараларны тәэмин итүдә катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсенә үз компетенциясе чикләрендә, сайлаучылар исемлекләрен төзү һәм тәгаенләү өчен, сайлаучылар турында мәгълүматлар тапшыруны тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына бу пункт белән күздә тотылган чараларны тәэмин итүдә катнашуны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары белән берлектә, билгеләнгән компетенция чикләрендә, түбәндәгеләрне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чорында, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын саклауны, шул исәптән сайлау комиссияләре бүлмәләрен, тавыш бирү урыннарын саклауны һәм, сайлау документларын йөрткәндә, сайлау комиссияләре соратуы буенча саклауны түләүсез нигездә тәэмин итәргә;

хокукка каршы килә торган агитация эшчәнлеген туктату, законсыз һәм ялган сайлау алды агитация материалларын эшләүне булдырмау һәм аларны кулланылыштан алу, күрсәтелгән материалларны эшләүчеләрне һәм таратучыларны ачыклау, хокукка каршы килә торган бүтән агитация эшчәнлегендә катнашучыларны билгеләү буенча кичектергесез чаралар күрергә, шулай ук ачыкланган фактлар һәм күрелгән чаралар турында тиешле сайлау комиссияләренә кичекмәстән хәбәр итәргә, материалларны үз вакытында судка җибәрергә.

6. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына сайлау комиссияләре бүлмәләрендә һәм тавыш бирү бүлмәләрендә янгын куркынычсызлыгының саклануын тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тәкъдим итәргә:

сак астында тоту урыннарында булган җинаять кылуда шикләнелүче һәм гаепләнүче гражданнар тавыш биргәндә, Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларын тәэмин итүдә сайлау комиссияләренә даими рәвештә булышлык күрсәтүне;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданы паспорты турындагы нигезләмәне, Россия Федерациясе гражданы паспорты бланкы үрнәген һәм тасвирламасын раслау хакында» 1997 ел, 8 июль, 828 нче карары белән расланган Россия Федерациясе гражданы паспорты турындагы нигезләмәнең 21 нче пунктын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту урыннарында булган Россия Федерациясе гражданнарына сайлауларда яки референдумда катнашу өчен белешмә бирү тәртибе турында» 2003 ел, 2 июль, 391 нче карарын үтәү чараларын күрүне.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль законның 47 статьясындагы 7 нче пункт, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 57 статьясындагы 3 өлеш нигезендә, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау кампаниясе чорында, сайлау алды агитациясен үткәрү өчен тиешенчә эфир вакыты һәм басма майдан бирергә бурычлы төбәк дәүләт вакытлы басмалары, теле- һәм (яки) радиотапшырулар гамәлгә ашыручы төбәк дәүләт оешмалары исемлекләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрергә, шулай ук Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә әлеге чараларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

9. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына бу карарның 8 нче пунктында күрсәтелгән исемлекләрне формалаштыру өчен кирәкле теле- һәм (яки) радиотапшырулар гамәлгә ашыручы оешмалар турындагы, сайлауларны билгеләү хакындагы карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә бер ел кала эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен, федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр һәм (яки) субвенцияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтелгән һәм (яки) аларның устав (җыелма) капиталында сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе субъектлары) өлеше (кертеме) булган вакытлы матбугат басмалары хакындагы мәгълүматларны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә тапшыруны гамәлгә ашырырга.

10. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә экстремистлык һәм хокукка каршы башка агитация эшчәнлеген, шул исәптән социаль, раса, милли, дини нәфрәт һәм дошманлык уятучы

агитация эшчәнлеген туктату буенча кичектергесез чаралар күрүне, шулай ук ачыкланган фактлар һәм күрелгән чаралар турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә үз вакытында хәбәр итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына күрсәтелгән хокук бозулар турындагы материалларны судка үз вакытында җибәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

11. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министр-лыгына барлык дәрәҗәдәге сайлау комиссияләре мәнфәгатьләрендә элемтә хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән гомуми файдаланудагы элемтә челтәре сегментының өзлексез эшләвен тәмин итү буенча, шул исәптән Россия Федерациясенең «Сайлаулар» автоматлаштырылган дәүләт системасын эшләтү өчен чаралар күрергә.

12. Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына электрон тавыш бирү комплекслары файдаланылачак сайлау участокларының тавыш бирү урыннарын, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, территориаль һәм участок сайлау комиссияләре урнашкан биналарны резерв автоном энергия белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

13. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына бу карарның 12 нче пунктында күздә тотылган эшләр үткәрүне мониторинглауны тәэмин итәргә.

14. Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

сайлау комиссияләренә, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына теркәлгән кандидатларга тиешенчә эфир вакыты һәм басма мәйдан биргәндә, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, ФЗ-67 нче Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы таләпләрен бозган теле- һәм (яки) радиотапшырулар гамәлгә ашыручы оешмаларга, вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә карата үз вакытында тиешле чаралар күрүне;

Татарстан Республикасы территориясендә эшләнә һәм (яки) таратыла торган басма, аудио- һәм аудиовизуаль массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясе эчтәлеген, аның Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының сайлаулар турындагы законнары таләпләренә туры килү-килмәвен ачыклау максатларында анализлауны;

административ хокук бозулар турында эшләр кузгаткан һәм административ тикшерү үткәргән очракта, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү һәм (яки) тапшырулар алып баруга лицензияләр булу-булмау турындагы документларны, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлегенә карый торган башка материалларны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә соратулар буенча оператив рәвештә кертүне.

15. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе соратуы буенча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы тикшерү-ревизия хезмәтендә эшләү өчен командировкага белгечләр җибәрергә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр

министрлыгына, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсенә, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә әлеге чараларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлегенә – Татарстан Республикасы Милли банкына һәм «Россия Саклык банкы» ачык акционерлык җәмгыятенең «Татарстан Банкы» 8610 нчы бүлегенә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сораулары буенча, тиешле комиссияләр каршындагы тикшерү-ревизия хезмәтләре составында эшләү өчен командировкага белгечләр җибәрүне тәкъдим итәргә.

16. Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына, үзләренең компетенциясе чикләрендә, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

сайлаучылар вакытлыча була торган урыннарда Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлау участоклары оештыруны, шулай ук тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне тиешле сайлау комиссияләренә илтеп тапшыруны тәэмин итүне;

Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлау комиссияләрен һәм аларның резервын формалаштыруда булышлык күрсәтүне;

сайлау комиссияләренә түләүсез нигездә тавыш бирү өчен кирәкле урыннарны, алдан тавыш бирү өчен урынны кертеп, һәм сайлау документларын саклау урынын бирүне (шул исәптән бу урыннарны һәм сайлау документларын саклауны тәэмин итүне);

тавыш бирү урыныннан читтә тавыш бирү үткәргәндә, тиешле сайлау комиссияләренә төрле җирдән үтә ала торган транспорт чараларын җитәрлек санда бирүне;

сайлаучылар исемлекләрен төзү һәм тәгаенлау өчен, территориаль сайлау комиссияләренә сайлаучылар турында мәгълүматлар кертүне;

сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар, шулай ук элемтә чаралары һәм техник җиһазлар бирүне;

сайлау участокларын оештыруга һәм сайлау комиссияләрен формалаштыруга бәйле булган мәгълүматны, шулай ук сайлауларны әзерләү һәм үткәрү барышы, сайлау гамәлләрен кылу вакытлары һәм тәртибе, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатлар турындагы сайлау комиссияләре кертә торган мәгълүматны бастырып чыгаруны;

сайлау комиссияләренә аларның сайлау документларын эшләү буенча заказларын тиешле бюджетлар акчасы исәбеннән финанслана торган оешмалар өчен билгеләнгән тарифлар буенча үтәүдә булышлык күрсәтүне;

Россия Федерациясенең «Сайлаулар» автоматлаштырылган дәүләт системасының өзлексез эшләве өчен кирәкле норматив технологик шартлар тәэмин итүне;

сайлау участокларын инвалидларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга үз сайлау хокукларын тулысы белән тормышка ашырырга ярдәм итә торган махсус җайланмалар белән җиһазландыруны тәэмин итүне.

17. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары белән берлектә:

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны үткәрүдә булышлык күрсәтү һәм аларны әзерләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркемнәр оештырырга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, сайлау комиссияләре сораулары буенча, аларның компетенциясе кысаларында тикшерүләр үткәрүдә булышлык күрсәтергә.

18. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\447.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 20 июнь, 447 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны үткәрүдә булышлык күрсәтү һәм аларны әзерләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркем
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, эшче төркем җитәкчесе |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Вафин Адел Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Волкова Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гәрәев Раил Рүзәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Житәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары профессиональ белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасының Югары уку йортлары ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы житәкчесе |
| Зарипов Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Җаббаров Азат Галимжан улы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе житәкчесе – Татарстан Республикасының баш дәүләт теркәүчесе (килешү буенча) |
| Идиатуллин Артур Рево улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Ильясов Радик Мөдәррис улы | Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы (килешү буенча) |
| Калинкин Денис Геннадьевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кузьмин Андрей Владимирович | Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Мәһдиев Наил Гамбәр улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Майстренко Владимир Викторович | «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең гомумхәрби академиясе» Коры җир гаскәрләре хәрби уку-укыту фәнни үзәге» югары профессиональ белем бирү федераль дәүләт казна хәрби мәгариф учреждениесенең Казан югары хәрби команда училищесы (хәрби институты) (филиалы) башлыгы (килешү буенча) |
| Ощепков Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Погодин Сергей Николаевич | Татарстан Республикасы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сафиуллин Марат Әдип улы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры |
| Хәмәдишин Дәүфит Закир улы | Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмитов Динар Газиз улы | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хохорин Артём Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шакиров Фәршат Сәгыйть улы | Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы рәисе (килешү буенча) |
| Шәфигуллин Айрат Радин улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре (килешү буенча). |

F:\KARAR\2015\447_1.doc